| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |

№ 114/о

П Р И К А З — Б О Е Р Ы К

«29» 06 2016

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының дәүләт хезмәтләрен күрсәтү буенча аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 14 декабрендәге “Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 02 ноябрендәге “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында” № 880 карары белән расланган “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләрен күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү турында” № 946 карары басылып чыгуга бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 14 декабрендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында” № 222/о боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын төзүгә рөхсәтләр бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.3.2 пунктында “231-15-43” саннарын “231-14-28” саннарына үзгәртергә;

1.3.3 пунктында “: “Интернет” телекоммуникацияләр челтәрендә (алга таба – “Интернет” челтәре)” сүзләрен төшереп калдырырга;

2 бүлектәге таблицаның 2.5 пунктына түбәндәге эчтәлекле 2.5.7 пунктын өстәргә:

| | | |
|---|---|---|
| | “2.5.7. Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.<br>Гариза белән теркәлүче документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча кәгазьдә бирелә (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);<br>кулга тапшыру турында тамга белән, почта аша заказлы хат итеп.<br>Мөрәҗәгать итүче электрон документ рәвешендәге, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган гариза белән документларны гомуми файдаланыла торган мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрләре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре һәм Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрергә хокуклы”; | |

2.6 пунктында “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле кызыл юллар белән тулыландырырга:

“Мөрәҗәгать итүче тапшырырга тиеш булган, шушы Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда санап үтелгән, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела”;

2.14 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән күрсәтелгән объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына туры китереп үтемле булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү | Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган махсус яки башка төрле бина түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:<br>мөрәҗәгат итүченең һәм Бүлектәге вазифаи затның уңайлы урнашуын;<br>мөрәҗәгать итүчегә кирәкле документларны рәсмиләштерү мөмкинлеген һәм бу эшнең җайлылыгын;<br>телефон элемтәсен;<br>документларның күчермәләрен ясап алу мөмкинлеген;<br>язу-сызу кирәк-яракларының һәм А4 рәвешендәге кәгазьләрнең булуын.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга керү | |

| | | |
|---|---|---|
| тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыруга карата таләпләр | максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла”; | |

2.15 пунктындагы “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле бишенче кызыл юлны өстәргә:

“инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне үтүдә ярдәм күрсәтү.”;

2.15 пунктының “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында бишенче – унбишенче кызыл юлларны алтынчы-уналтынчы кызыл юллар итеп санарга;

3.3.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

“Гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны, шулай ук хокук көчү турындагы белдерүнамәне мөрәҗәгать итүче шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнарда һәм шушы Административ регламентта белдерелә торган таләпләрне үтәп, электрон рәвештә тапшыру хокукына ия.

Документлар электрон рәвештә тапшырылган очракта, гариза һәм аңа теркәлә торган документлар, шулай ук хокук көчү турында белдерүнамә гаризаны имзалаган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән таныкланган булырга тиеш.

Гаризага мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документларның исемлеге, шулай ук, мондый мөмкинлекне бирә торган юридик нигезләрне күрсәтеп, тапшырылмый торган документларның исемлеге теркәлергә тиеш.

Тапшырылмый торган документлар исемлегендә аларның исемнәре, аларны биргән органнар, теркәү номерлары, теркәү даталары, аерым очракларда, - аларда булган, тиешле гарызнамәләрне бирү өчен зарури булган белешмәләр күрсәтелә.”;

“Административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре” дигән 3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

5.1 пунктының икенче кызыл юлында “, яисә монополиягә каршы орган” сүзләрен өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының 2015 елның 14 декабрендәге “Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру буенча рөхсәтләр бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентын раслау турында” № 222/о-1 боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының капиталь төзелеш объектларын файдалануга тапшыру буенча рөхсәтләр бирүгә карата дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.4 пунктының “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 01 мартындагы “Объектны файдалануга кертү буенча рөхсәт алу өчен кирәкле булган документны билгеләү турында” № 175 карары белән” дигән алтынчы кызыл юлын көчен югалткан дип танырга;

5.1 пунктының икенче кызыл юлында “, яисә монополиягә каршы органга”

сүзләрен өстәргә;

2.4 пунктының “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасын түбәндәге эчтәлекле кызы юл белән тулыландырырга:

“Дәүләт хезмәте күрсәтүнең вакытын туктатып тору каралмаган”;

2.5 пунктындагы “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

“Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза белән теркәлүче документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе буенча кәгазьдә бирелә (җибәрелә) ала:

шәхсән (ышанычнамә нигезендә мөрәҗәгать итүче исеменнән гамәл кылучы зат тарафыннан);

кулга тапшыру турында тамга белән, почта аша заказлы хат итеп.

Мөрәҗәгать итүче электрон документ рәвешендәге, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган гариза белән документларны гомуми файдаланыла торган мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрләре аша, шул исәптән “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәре һәм Бердәм дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәрергә хокуклы”;

2.6 пунктындагы “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында түбәндәге эчтәлекле кызыл юлларны өстәргә:

“Мөрәҗәгать итүче тапшырырга хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм тапшыру тәртибе әлеге Административ регламентның 2.5 пунктында билгеләнде.

Мөрәҗәгать итүчедән югарыда саналган, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм бүтән оешмалар карамагында булган документларны таләп итү тыела.”;

2.14 пунктын түбәндәгечә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| “2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән күрсәтелгән объектларның Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турындагы законнарына туры китереп үтемле булуын тәэмин итүгә, мондый хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүматларны урнаштыруга карата таләпләр | Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган махсус яки башка төрле бина түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:<br>мөрәҗәгат итүченең һәм Бүлектәге вазифаи затның уңайлы урнашуын;<br>мөрәҗәгать итүчегә кирәкле документларны рәсмиләштерү мөмкинлеген һәм бу эшнең җайлылыгын;<br>телефон элемтәсен;<br>документларның күчермәләрен ясап алу мөмкинлеген;<br>язу-сызу кирәк-яракларының һәм А4 рәвешендәге кәгазьләрнең булуын.<br>Инвалидлар өчен дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга каршылыкларсыз үтеп керү, шул исәптән объектларга каршылыкларсыз керү һәм алардан чыгу, шулай ук дәүләт хезмәте күрсәтелә торган урынга керү максатларында объект буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү турында визуаль, текстлы һәм мультимедияле мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләргә уңайлы булган урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә | |

| | | |
|---|---|---|
| | алып урнаштырыла”; | |

2.15 пунктында “Стандартка карата таләпләрнең эчтәлеге” графасында:

түбәндәге эчтәлекле алтынчы кызыл юлны өстәргә:

“инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәтләр алуга комачау итүче киртәләрне үтүдә ярдәм күрсәтү.”;

“Дәүләт хезмәте Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә (алга таба - КФҮ) күрсәтелергә мөмкин” дигән унбишенче кызыл юлны түбәндәгечә бәян итәргә:

“Дәүләт хезмәте күпфункцияле үзәкләрдә, шулай ук читтән торып эшләү урыннарында күрсәтелми.”;

3.1.1 пунктының “Административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре” дигән 6 пунктчасын көчен югалткан дип танырга;

“Административ процедураларны электрон рәвештә башкару үзенчәлекләре”дигән 3.7 пунктны көчен югалткан дип танырга;

3.9.1 процедурасының бишенче кызыл юлында “яки дәүләти яки муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю.Латыйповага боерыкның дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына һәм законда билгеләнгән тәртиптә “Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры” дәүләт мәгълүмат системасын алып бару буенча вәкаләт бирелгән органга җибәрелүен тәэмин итәргә.

4. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезммәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С.Миңнехановага, шушы боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынганнан соң, ун эш көне эчендә аның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору җаваплылыгын үз өстемә алам.

Министр ОТДЕЛ РЕГЛАМЕНТА И КОНТРОЛЯ №1 И.Ә.Фәйзуллин